ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 04.08.2025 1259 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә ирекле халык дружиналары эшчәнлеген оештыру турында» 2025 елның 1 июлендәге 1091 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге 44-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җәмәгать тәртибен саклауда гражданнарның катнашуы турында» 2015 елның 16 гыйнварындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы территориясендә ирекле халык дружиналары эшчәнлеген оештыру турында» 2025 елның 1 июлендәге 1091 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 бүлегендәге 11пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Район штабының карары беркетмә белән рәсмиләштерелә һәм утырышта рәислек итүче, шулай ук район штабы утырышы үткәрелгән көннән алып өч эш көне эчендә район штабы секретаре тарафыннан имзалана. Район штабы әгъзаларының аерым фикере язма рәвештә бәян ителә һәм район штабы карарына теркәлә».

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Э.Р. Әхмәдиева

Лист согласования к документу № 1259 от 04.08.2025
Инициатор согласования: Каретина К.Д. Главный специалист
Согласование инициировано: 06.08.2025 16:26

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Ахмадеева Э.Р. | | Подписано 06.08.2025 - 21:34 | - |



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН